**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «14» маеннан № 116

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирлеге гражданнарына өченче һәм күбрәк бала тудырганда бер тапкыр түләнә торган акчалата түләү турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында демографик вәзгыятьне яхшырту һәм халык саны кимүнең тискәре тенденцияләрен җиңү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирлегендәге гражданнарга өченче һәм күбрәк бала тудырганда социаль ярдәм чарасы итеп түбәндәге күләмдә бер тапкыр түләнә торган акчалата түләү билгеләргә:

- гражданнар өченче һәм күбрәк бала(лар) тудырганда 15 000,00 сум.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирлегендәге гражданнарга өченче һәм күбрәк бала тудырганда бер тапкыр түләнә торган акчалата түләүне тормышка ашыру тәртибен расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарда күрсәтелгән социаль ярдәм чарасын бирү өчен җирле бюджет акчаларыннан финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ИНН 1631003397 ОГРН 1051660041740 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «14» маеннан
116 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирлеге гражданнарына өченче һәм күбрәк бала тудырганда бер тапкыр түләнә торган акчалата түләүне тормышка ашыру тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гражданнары өчен өченче һәм күбрәк бала туганда бер тапкыр акчата түләү бирү механизмын билгели.

2. 15000,00 сум күләмендәге бер тапкыр акчалата түләү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гражданнарына өченче һәм күбрәк бала туганда, түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

- бала тууның дәүләт теркәве ата-аналарның (яки ата-аналарның берсенең) яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында булырга тиеш.

2.1. Бер тапкыр түләү алу өчен кирәкле документлар исемлеге:

- бер тапкыр түләү билгеләү турында гариза;

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык - ата-ананың берсенең паспорт күчермәсе;

- акча күчерү өчен банк реквизитлары;

- баланың туу турында таныклык күчермәсе;

Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә уздырылган җыеннар нигезендә үзара салым түләү турында белешмә;

- салымнар буенча бурычлары булмау турында белешмә.

3. Бер тапкыр түләүне билгеләү өчен законлы вәкил (мөрәҗәгать итүче) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба - вәкаләтле орган) тапшыра:

- бер тапкыр түләү билгеләү турында гариза (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтадагы форма буенча);

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтадагы форма буенча);

- бер ата-ананың паспорт күчермәсе;

- акча күчерү өчен банк реквизитлары;

- баланың туу турында таныклык күчермәсе;

- Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә уздырылган җыеннар нигезендә үзара салым түләү турында белешмә;

- салымнар буенча бурычлары булмау турында белешмә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Башкарма комитеты 5 эш көне эчендә бер мәртәбә акчалата түләү бирү турында/бер мәртәбә акчалата түләү бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм муниципаль хокукый акт боерык формасында чыгарыла.

5. Мөрәҗәгать итүчеләрнең кредит оешмаларында ачылган шәхси

счетларына бер тапкыр акчалата түләү суммаларын күчерү, бер тапкыр акчалата түләү билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә саналган утыз көнлек срок эчендә башкарыла.

6. Бер тапкыр акчалата түләү бирүдән баш тартуның нигезе - аны алу хокукына комачаулык ясаучы документларның булмавы.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «14» маеннан
116 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гражданнарына өченче һәм күбрәк бала тудырганда бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә 1 нче кушымта

20__ елның __ _________ бер тапкыр түләү билгеләү турында гариза

Мин ____________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта))

| Шәхесне таныклый торган документның исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелү вакыты |
|---|---|---|---|
| | | | |

Адрес буенча теркәлгән: ___________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индекс, телефон, электрон почта адресы күрсәтелгән)

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының __________ _______ номерлы карарына таянып, Яңа Чишмә муниципаль районы гражданнарында өченче һәм күбрәк бала туганда бер тапкыр акчалата түләү бирүне сорыйм

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), туу датасы)

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), туу датасы)

Мин мәгълүмат алуга, шул исәптән социаль ярдәм чаралары күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында мәгълүмат алуга ризамын

(почта адресына хат, электрон почта адресына электрон почта аша)

Дата_____________ ________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «14» маеннан
116 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гражданнарына өченче һәм күбрәк бала тудырганда бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә 2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,______________________________________________________________,
(Ф.И.Ат.и. (соңгысы - булган очракта) тулысынча)

(контакт мәгълуматы: телефон номеры, электрон почта адресы яисә шәхси мәгълүматлар субъектының почта адресы)

гражданнарга өченче һәм күбрәк бала тудырганда бер тапкыр акчалата түләү билгеләү максатларында, минем һәм минем балигъ булмаган балаларымның шәхси белешмәләрен (белешмәләрне) һәм шәхси мәгълүматларын автоматлаштыру чараларын кулланып яисә алардан башка җыюны, язуны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңарту, үзгәртүне), мәгълүмат алу, куллану, тапшыруны (тарату, тәкъдим итү, рөхсәт бирү), обезличивание, чикләү, юк итү, юкка чыгаруны, кулланмыйча) эшкәртүгә ризалык бирәм.

(Ф.И.Ат.и. (соңгысы - булган очракта), туу датасы)

фамилиясен, исемен, атасының исемен; туу датасын; гаилә хәлен; паспорт мәгълүматларын; теркәү һәм яшәү урыны адресын; контактлы телефон номерын.

Шәхси мәгълүматларны, балигъ булмаган балалар турында белешмәләрне эшкәртүгә ризалык, социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә документлар саклау өчен архив законнарында билгеләнгән срок узганчы гамәлдә була.

(дата) (фамилиясе, исеме, атасының исеме) (соңгысы - булган очракта) (имза)